РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«11» март 2021 г. г. Альметьевск № 47

««Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазифасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне бирү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2017 елның 25 сентябрендәге 197 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 26 декабрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. ««Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазифасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мелкәт һәм мелкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне бирү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2017 елның 25 сентябрендәге 197 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- карарга 1 нче кушымтада 3 пунктның «г» пунктчасында «оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы пайлар,» сүзләреннән соң «цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәргә».

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU)» һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет»

Заказ № 2625

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Парфилова Н.В.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов